СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
26.04.2019

Зеленодольск
шәһәре

КАРАР
№ 378

Зеленодольск муниципаль районының “Финанс-бюджет палатасы" муниципаль учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында

«Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтеваның «Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» Муниципаль учреждениесе турында Нигезләмә проекты турында мәгълүматны тыңлап һәм карап, Татарстан Республикасы «муниципаль район» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. "Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы" Муниципаль учреждениесе турында Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 13 гыйнварындагы 28нче номерлы карары (карарның 2нче пункты) белән расланган "Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы" Муниципаль учреждениесе турындагы нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Зеленодольск муниципаль
районы башлыгы,
Совет рәисе **А.В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы карарына кушымта
2019 елның 26 апреле № 378

«ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФИНАНС-БЮДЖЕТ ПАЛАТАСЫ» МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» Муниципаль учреждениесе (алга таба - Палата) Зеленодольск муниципаль районы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына (алга таба – җирле бюджетлар) хезмәт күрсәтү һәм җирле бюджет акчасы белән идарә итү максатларында төзелгән даими эшләүче җирле үзидарә финанс органы булып тора.

Палата муниципаль учреждение рәвешендә Зеленодольск муниципаль районы Советы тарафыннан төзелә. Тулы исеме - "Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы” Муниципаль учреждениесе.

1.2. Палата үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга, Зеленодольск муниципаль районы Уставына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Палата юридик зат буларак мөстәкыйль баланска, гамәлдәге законнарга ярашлы ачыла торган исәп-хисапка, мөһергә һәм үз исеме белән Зеленодольск муниципаль районы гербы ясалган бланкка ия.

1.4. Палатаның урнашу урыны (юридик адресы) : 422540, Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 38нче йорт.

2. Палатаның бурычлары.

2.1. Палатаның төп бурычлары булып тора:

2.1.1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә бердәм финанс, бюджет һәм салым сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2.1.2. Тиешле тәртиптә җирле бюджет проектларын төзү һәм аларны тәэмин итү;

2.1.3. Зеленодольск муниципаль районы җирле бюджетын һәм консолидацияләнгән бюджетын башкару турында хисаплар төзү;

2.1.4. муниципаль алынмалар программасын эшләү һәм аларны тиешле тәртиптә гамәлгә ашыру;

2.1.5. башкарма власть федераль органнары, Татарстан Республикасы башкарма власть органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм башка оешмалар белән элемтәдә торуны тәэмин итү;

2.1.6. финанс-бюджет өлкәсендә эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру һәм җирле бюджетлар акчаларының Баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны анализлау.

3. Палатаның функцияләре.

3.1. Палата үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне башкара:

3.1.1. бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм гамәлгә ашыра;

3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә социаль-икътисади үсеш фаразлауларын тиешле тәртиптә эшләүдә катнаша;

3.1.3. җирле бюджетларның табыш өлешен башкаруда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә һәм территориаль органнары эшчәнлеген координацияли, салым һәм салым булмаган түләүләргә мониторинг уздыра;

3.1.4. муниципаль максатчан программаларны әзерләүдә катнаша, аларны җирле бюджетлар исәбенә тиешле тәртиптә финанслауны тәэмин итә;

3.1.5. Зеленодольск муниципаль районы Советының бюджет һәм башка муниципаль хокукый актлар турында карарлары проектларын эшләүдә тиешле тәртиптә катнаша;

3.1.6. билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының бюджет һәм башка муниципаль хокукый актлар проектларын эшләүдә катнаша;

3.1.7. үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар әзерли һәм билгеләнгән тәртиптә чыгара;

3.1.8. җирле бюджетлар проектларын әзерли һәм аларны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим итә ;

3.1.9. Зеленодольск муниципаль районының консолидацияләнгән бюджетын фаразлауны әзерли;

3.1.10. үз компетенциясе кысаларында Зеленодольск муниципаль районы җирле бюджетлары һәм консолидацияләнгән бюджеты үтәлеше турында хисаплар төзи ;

3.1.11. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап бирә;

3.1.12. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына хисап бирә;

3.1.13. җирле бюджетларның бюджет язмаларын төзи;

3.1.14.финанс-бюджет өлкәсендә Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыра;

3.1.15. җирле бюджетлар акчаларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс тикшерүе һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны анализлый;

3.1.16. җирле үзидарә органнары бүлекчәләрен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша; Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары аппаратларын тотуга ассигнованиеләр күләме һәм чикле саны турында тәкъдимнәр әзерли; муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

3.1.17. бюджет чыгымнары нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр әзерли;

3.1.18. салым сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнаша;

3.1.19. җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын куллану мәсьәләләре буенча җирле салымнар һәм җыемнар турында аңлатмалар бирә;

3.1.20. муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе һәм урнаштыру өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыра;

3.1.21. муниципаль бурыч алулар структурасын формалаштыру өлкәсендә бердәм сәясәт төзи һәм тормышка ашыра;

3.1.22. тиешле тәртиптә муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмитенты сыйфатында чыгыш ясыйг, муниципаль займнар чыгару һәм урнаштыру шартларын эшли

3.1.23. муниципаль бурыч китабын алып бара;

3.1.24. муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

3.1.25. бюджет турында Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган акча лимиты кысасында һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бюджет кредиты бирүне үтәүне тәэмин итә;

3.1.26. муниципаль эчке бурыч структурасын камилләштерү һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнарын оптимальләштерү буенча кирәкле чараларны гамәлгә ашыра;

3.1.27.бюджет акчаларын алучылар, шул исәптән бюджет кредитларын һәм муниципаль гарантияләрне алучылар тарафыннан бюджет акчаларын бүлеп бирү, алу, максатчан файдалану һәм кире кайтаруны контрольдә тота;

3.1.28. җирле бюджетларның керемнәре чыганаклары реестрын формалаштыра һәм алып бара;

3.1.29.Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүче һәм алучы функцияләрен башкара;

3.1.30. гамәлдәге законнарда каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

4. Палатаның хокуклары.

4.1. Палата хокуклы:

4.1.1. кирәкле материалларны соратып алырга һәм билгеләнгән тәртиптә алырга:

җирле бюджет проектларын эшләргә;

Зеленодольск муниципаль районы консолидаөияләнгән бюджеты фаразлары исәпләргә;

җирле бюджетларның үтәлеше турында хисап төзергә;

Зеленодольск муниципаль районы консолидацияләнгән бюджетын үтәү буенча хисап төзергә;

4.1.2. тиешле тәртиптә Палата комптенециясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле белешмәләрне соратып алырга;

4.1.3. закон нигезендә бюджет законнарын бозучыларга мәҗбүр итү чараларын кулланырга;

4.1.4. салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә салымнар һәм җыемнар түләү срокларын үзгәртү турында карарларныв килештерүгә.

5. Палатаның эшен оештыру.

5.1. Палатаны палата эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче җитәкче җитәкли. Палата җитәкчесе Зеленодольск муниципаль районы башлыгы тәкъдиме белән Зеленодольск муниципаль районы Советы тарафыннан билгеләнә.

Палата бүлекләрдән тора: бюджет бүлеге, исәп һәм хисап бүлеге, икътисадый анализ һәм фаразлау бүлеге, бюджетлар белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге. Җитәкче ике урынбасар бар.

5.2. Палата җитәкчесе урынбасарлары Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән язма килешү буенча Палата җитәкчесе итеп билгеләнә.

5.3.Палата җитәкчесе:

- бедәм башлангыч нигезендә палата эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
- палата хезмәткәрләре арасында вазыйфаларны бүлә;
- билгеләнгән тәртиптә палата хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә;

- законнар, Зеленодольск муниципаль районы Уставы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5.4. Палатаны тотуга киткән чыгымнарны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджеты хисабына башкарыла.

5.5.Палатадагы хезмәт Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәт булып тора. Палатада муниципаль хезмәт вазыйфасында хезмәт башкаручы затлар муниципаль хезмәткәрләр дип атала.